РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

26 июнь 2023 ел

Буа шәһәре

№ 5-47

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Советының 2014 елның 12 ноябрендәге 4-42 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау регламенты турында» карары белән расланган (2018 елның 30 мартындагы 2-30 номерлы, 2018 елның 22 октябрендәге 5-34 номерлы, 2019 елның 01 августындагы 2-43 номерлы карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. VII бүлектә:

7.4.2 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.4.2. Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Рәисе мөрәҗәгатьләрен карау буенча йөкләмәләрнең үтәлеше 15 көнгә кадәр карау вакыты белән аерым контрольгә куела.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов